**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 05.10.2020** **№ 764**

**2020 елның III кварталына салым салынырга тиешле гражданнар кеременнең һәм мөлкәте бәясенең чик күрсәткечләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында" Татарстан Республикасы Законы һәм күрсәтелгән Законга кушымтада бәян ителгән һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2020 елның 29 июнендәге 351/пр номерлы "Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2020 елның икенче яртыеллыгына бәясе нормативы һәм 2020 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында" боерыгына таянып, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның III кварталына гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен чик күрсәткечләр билгеләргә:
1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чикләре:
1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 346 878,50 сум;
1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 1 714 209 сум;
1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 2 203 983 сум;
1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 2 938 644 сум;
1.1.5. Биш кешелек гаилә өчен - 3 673 305 сум;
1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 4 407 966 сум;
1.1.7. Җиде кешелек гаилә өчен - 5 142 627 сум;
1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык керем күләме:
1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 16 145,30 сум;
1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 10 274,28 сум;
1.2.3. Өч кешелек гаилә өчен - 8 806,53 сум.
2. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 бүлекләрендә күрсәтелгән чикләрне гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарын бирүгә исәпкә кую һәм аларга бирү максатларында аз керемлеләр дип тану өчен кулланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин